


# Иҗади сәхифә

декабрь, 2021

Сәхифәне оештыручылар: 3 нче мәктәпнең татар теле
һәм әдәбияты укытучылары методик берләшмәсе


## Ананың балага биргән иң зур бүләге - тел

2021 нче ел – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы. Безнең мәктәптә бу ел аеруча кызыклы булды. Укучылар мәктәптә укыган төрле милләт балалары белән таныштылар, аларның телләрендә башкарылган җыр- шигырьләрне кызыксынып тыңладылар. Бездә 6 милләт вәкиле балалары укыса да, укучылар үзара бик тату яшиләр, бер-берсен хөрмәт итәләр.

Бу ел дәвамында мәктәптә төрле кызыклы чаралар үткәрелде, аларда мәктәпнең төрле сыйныф укучылары актив катнаштылар.

Мәктәбебездә дә бу зур вакыйганы ачып җибәрү тантанасы булып үтте. Иртәдә мәктәп шау-гөр килде. Фойеда килгән укытучыларны һәм укучыларны төрле телләрдә сәламләп каршы алдылар. Телләр турында әйтелгән матур сүзләр дә төрле телләрдә яңгырады. Укучыларга телләр турында кызыклы мәгълүматлар җиткерелде. Төрле милләт көйләрен башкардылар, ә тәнәфестә рус һәм татар халык уеннарын уйнадылар, төрле милли җырларны тыңладылар. Бәйрәм бик кызыклы булды!




Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елының ачылу тантанасы районыбызның гимназиясендә дә үтте. Бу чарада туган тел һәм әдәбияты укытучылары белән бергә безнең укучылар да актив катнаштылар.

Чарада районда яшәгән төрле милләт балалары катнаштылар: биеделәр, җырладылар, шигырь сөйләделәр. Безнең мәктәп укучысы Сәидов Нариман да сәхнәдә чыгыш ясады. Ул үзенең туган таҗик телендә шигырь сөйләде. Нариманның туган телен камил белүе, шул ук вакытта татар телен дә теләп укуы, рус телендә дә сөйләшә алуы, инглиз телен дә өйрәнүе сокландыра.

Бәйрәм искиткеч матур узды һәм укучыларның күңелләрендә калды.

Мәктәбебездә семинар булып узды. Анда мәктәпләрдән төрле фән укытучылары катнашты. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары Җәләева Гөлгенә Галимҗан кызы һәм Тимиркаева Ольга Анатолий кызы үзләренең мастер-классларын күрсәттеләр. Гөлгенә Галимҗан кызы “Театр түгәрәге утырышы” дигән темага сыйныф сәгате үрнәген тәкъдим итте. Ольга Анатолий кызы укучыларга театр сәнгатен дәрестә куллану үрнәкләре белән таныштырды. Төрле уеннар аша укучылар сәхнәләштерүгә ирештеләр. Шулай ук районда үткәрелгән туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучыларының семинары булып узды. Анда мәктәбебезнең укытучылары актив катнашты. Әхмәтшина Л.М., Гарфеева А.М., Җәләева Г.Г. һәм Тимиркаева О.А. үзләренең мастер-классларын әзерләделәр.

Лариса Михайловна “Татар телен укытуда ”көтелмәгән кунак” алымы белән таныштырды. Гөлгенә Галимҗан кызы “Образлы сурәтләү” темасына чыгыш ясады. Альбина Миңлегол кызы уен алымнарын күрсәтте. Ольга Анатольевна “Фигыльләрне уен аша өйрәнү” темасына мастер - класс тәкъдим итте.Укытучылар күрсәткән мастер-классларга уңай бәя бирелде.







Безнең мәктәптә әти-әниләр белән эш тыгыз бәйләнештә. Иң кызыклылырының берсе- бу әти-әниләр оештырган мастер-класслар. 5 нче сыйныф укучылары өчен Тимиркаева Эльвира Мәгдән кызы калфак тегү һәм аны бизәү буенча мастер- класс үткәрде. Укучылар бу эшне бик ошаттылар. Аларны килеп чыккан милли баш киеме аеруча сокландырды, ә бизәп куйгач, тагы да матур булды калфаклар. Әти-әниләр белән эшләнгән эш, һичшиксез, үз җимешләрен бирә һәм истә кала. Бердәмлектә көч!







3 нче санлы мәктәптә танылган якташ язучыбыз Рәшит Гәрәй истәлегенә кичә үтте. Бу кичәнең кунагы Якиева Л.Г. на булды. Ленизза Габбас кызы Рәшит Гәрәй турында кызыклы итеп сөйләде, музей экспонатлары белән таныштырды. Лариса Михайловна музей турында сөйләде. Кичәне 1 нче сыйныф укучылары җыр белән башлап җибәрделәр, ә башка сыйныф укучылары Рәшит Гәрәйнең шигырьләрен сөйләделәр, җырлар башкардылар. Кичә укучыларда бик күп тәэсир калдырды.

Дәресләрдән соң да укучыларыбыз кул эшләре ясау белән шөгыльләнәләр. Алар бу истәлекле елны каршылап, төрле өй кирәк– яраклары әзерлиләр, уенчыклар ясыйлар һәм аларны милләт орнаментлары белән бизиләр.






Милли бәйрәмебез Сабантуйны да үткәрү - укучылар өчен көтеп алынган көн, чөнки бу бәйрәмдә төрле бәйгеләрдә катнашып бүләкләр алырга була. Җыр- бию дә күңелне күтәрә.







“Мин татарча сөйләшәм” акциясендә дә укучылар кызыксынып катнашалар, алар очраган кешеләр белән татарча сөйләшергә тырышалар, төрле сораулар бирәләр, ә олылар биргән сорауларга үзләре дә җавап бирәләр.



# Телләр өйрәнү кирәкме?

Телләрне өйрәнү кирәкме? Минемчә, без үз туган телебезне белергә тиеш. Кая гына барсак та, ул безнең туган илебезнең, туган ягыбызның бер өлеше булып калачак. Телне сатып алып та, сатып җибәреп тә булмый, аны сакларга һәм хөрмәт итәргә кирәк. Минем әйтәсе килгәнем шул: туган телне өйрәнү бик кирәк, соңрак укенечкә калмасын өчен.

Гобәйдуллин Рамир, 9 нчы сыйныф укучысы

Тәлләрну өйрәнү бик кирәк, чөнки ул кешенең фикерләү сәләтен үстерә. Телләр белгән кеше кыен хәлдә калмаячак. Ә туган телне өйрәнү сине патриот буларак күрсәтә һәм синең яшәгән урыныңны, гореф-гадәтләреңне, телеңне хөрмәт итүеңне тагы бер кат ача.

Лакиман Виолетта, 9 нчы сыйныф укучысы

Бүгенге тормышта телләрне өйрәнү зур игътибар үзәгендә тора. Кешеләр бик күп төрле телләрдә сөйләшәләр. Ә алар белән сөйләшү, аларны аңлау өчен телләрне өйрәнергә кирәк.

Телләрне өйрәнү интеллект үсешенә ярдәм итә.Туган телне аеруча белергә кирәк, чөнки тормышта ул ярдәм итәчәк. Телләрне белсәң, син башка кешеләр алдында өстенрәк буласың. Ә инглиз телен белү – чит телдә кирәк булачак.

Шагапова Софья, 8 нче сыйныф укучысы

Туган телем- татар теле. Ул әти-әни, туганнар, дуслар белән аралашу өчен кирәк. Татар телен белүче төрки телләрне дә аңлый ала.

Рус теле- катлаулы тел. Аны да яхшы белергә кирәк, чөнки ул һәркайда кирәк. Мин инглиз телен дә өйрәнәм. Бу телне белгән кеше күп илләрдә сәяхәт итә ала. Мин тагын корея телен өйрәнергә уйлыйм, ул миңа киләчәктә эштә кирәк була.

Минем уйлавымча, кешегә 2-3 телне белергә кирәк. Телләрне өйрәнгәч, дөньяны күрергә, аны өйрәнергә мөмкин. Тел белү – хезмәт юлында да кирәк.

Иванова Лилия, 8 нче сыйныф укучысы

Татар теле дәресенә безнең сыйныфтан барлыгы 12 укучы йөри. Бу – безнең төркем. Татар теле дәресләрен без бик яратабыз һәм һәрвакыт көтеп алабыз. Дәресләрдә без төрле-төрле һәм бик кызыклы биремнәр үтибез, дөрес һәм матур итеп татарча сөйләшергә өйрәнәбез. Быел әле төркемебез белән укытучыбыз Лариса Михайловна оештырган түгәрәккә дә йөрибез. Түгәрәктә матур хикәяләр уйлап чыгарабыз, төрле җырлар өйрәнәбез һәм әкият куярга әзерләнәбез. Шул әкиятне сәхнәдән күрсәтер өчен, бик тырышып сүзләрен кабатлыйбыз. Төркемебез белән татар теле дәресләрен көтеп алабыз. Татар теле - минем дә иң яраткан дәресем.

Вәлиева Ләйсән, 3нче сыйныф укучысы

Минем барлыгы биш дус кызым бар. Менә алар: Ләйсән, Влада, Ариадна, Амилә, Алиана. Без һәрвакыт бишәү: бергә аралашабыз, уйныйбыз, дәрес әзерлибез. Дусларым күп булу миңа бик ошый. Без үзебезгә ошаган дәресләр турында сөйләшәбез. Мин дусларыма үземнең яраткан дәресләрем - татар теле һәм инглиз теле дәресләре турында сөйлим. Миңа бу дәресләрнең икесе дә бик ошый. Мин хәзер татарча да, инглизчә дә яхшы аңлыйм, сөйләшергә дә тырышам. Мин үземнең укытучыларымны да бик яратам. Минем әнием дә - укытучы. Укытучы хезмәте - ул бик авыр хезмәт. Мин аны дусларыма да әйтәм.

Газизова Амалия, 3 нче сыйныф укучысы

Минем апамның исеме – Вероника. Ул 5 нче А сыйныфында укый. Шулай ук апам музыка мәктәбендә дә укый. Апам буш вакытта кулына гел телефон ала, анда төрле уеннар эзләп таба. Уйный башласа, бөтен дөньясын оныта. Әти белән әни күрсәләр, аны ачуланалар да. Шуңа күрә ул миңа телефонда уйнаганын әйтмәскә куша. Телефонда озак уйнау зарарлы икәнен барыбыз да беләбез. Апам да белә, ләкин барыбер уйный.

Вахнин Алексей, 3нче сыйныф укучысы





**Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган Грантта безнең мәктәп җиңү яулады. Анда театр сәнгатен үстерүгә зур игътибар бирелде. Шул уңайдан мәктәптә күп спектакльләр күрсәтелде.**

Башлангыч һәм 5нче сыйныф укучыларының татар төркемендә укучы балалар Абдулла Алишның “Сертотмас үрдәк” әкиятен сәхнәләштерделәр. Катнаштылар:
сертотмас үрдәк –Ханова Әдилә,
автор - Сәхәпова Мәрьям,
хуҗа – Шәкүров Камил,
эт –Бармутин Раил,
төлке – Рахманова Зөлфия,
керпе – Галиева Әдилә,
төлке баласы – Юнысова Диләрә,
куян – Гыйләҗева Әдилә,
бүре – Фатхуллин Рәфил,
аю – Маликов Булат.
Мәктәп укучылары курчак театрын бик яратып карадылар, көчле алкышларга күмделәр.



Ә 5нче сыйныфның рус төркемендә укучы балалар “Өч кыз” дигән татар халык әкиятен күрсәттеләр. Укучылар үзләре җырлар уйлап чыгарырга ярдәм иттеләр, бирелгән рольләрне сәнгатьле итеп башкарырга өйрәнделәр. Әкият бик кызыклы килеп чыкты, караган укучыларда ул уңай тәэсир калдырды.





Татар теле укытучылары җитәкчелегендә мәктәптә күп спектакльләр куела. Ел саен укучыларыбыз, аеруча төрле милләт балалары, төрле сәхнә әсәрләрендә катнашалар. Алар төрле телләрдә куела.





***

Татар теле – минем туган телем. Мин татарча яхшы аңлыйм, ләкин начар сөйләшәм. Минем татарча яхшы сөйләшергә өйрәнәсем килә. Шуңа күрә дә мин татар теле дәресләрен көтеп алам, аларны бик яратам. Укытучыбыз Лариса Михайловнаны да бик яратам. Татар теле дәресләренә без мәктәпнең икенче катына менәбез, икенче катка мену безнең өчен бәйрәм шикелле. Без быел татарча спектакль дә әзерлибез. “Койрыклар” әкиятен сәхнәдә куярга әзерләнәбез. Без бу әкиятне бераз үзгәрттек тә әле, яңа әкият килеп чыкты. Анда яңа геройлар да бар. Ә минем үземә Карт Керпе ролен бирделәр. Миңа үземнең ролем бик ошый. Барлык сүзләр дә гел татар телендә генә. Без саф татарча спектакль куячакбыз.

Федотов Вилдан, 3В сыйныф укучысы

